Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Яңа Бүләк авылы **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«10» декабрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Тукай муниципаль районы "Яңа Бүләк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегенең Советы 30.11.2019 ел, № 43/1 «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында" нигезләмәне раслау хакында» карары белән Яңа Бүләк авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2026 елда яшәү урыны буенча Яңа Бүләк авыл җирлеге Яңа Бүләк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Хәрби Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Яңа Бүләк авылында янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру, янгын сүндерү колонкасы һәм янгын сүндерү җиһазы сатып алу);

2. Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Яңа Бүләк авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Яңа Бүләкавылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Бүләк авыл җирлеге Башлыгы М.С. Сагетдинов